КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 гыйнвар г.Казань № 6

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «133», «3 002,333» саннарын туры килү буенча «148», «3 358,171» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.1 пунктта:

$4.1.83^{1}$ һәм $4.1.83^{2}$ 4.1.38 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.38. Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләүне, саклау, эшкәртү һәм сатуны лицензияләүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.1.83^{1}$ һәм $4.1.83^{2}$ пунктчаларын өстәргә:

«$4.1.83^{1}$. Кара һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүне гамәлгә ашыра.

$4.1.83^{2}$. Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында төбәк проектларын гамәлгә ашыру буенча проект эшчәнлеген гомуми координацияләүне тәэмин итә, шулай ук аларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына консультацион-методик ярдәм күрсәтә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 23 июль, 325 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы структурасы

